Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Яңа Арыш авыл җирлеге составына керүче Яңа Арыш авылы
торак пунктында үткән гражданнар җыенын нәтиҗәләре турында

# КАРАР

2020 елның 27 ноябре №1

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе нигезендә 2020 елның 26 нчы, 27 нче ноябрендә түбәндәге сораулар буенча уткәрелгән гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында беркетмә төзелде: «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең Яңа Арыш авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Яңа Арыш авылында юллар ремонты өчен вакланган таш сатып алуга;
- транспорт хезмәтләренә түләүгә;
- кышкы чорда Яңа Арыш авылында юлларны карап торуга;
- янгын сүндерү җиһәзе сатып алу;
- энергияне аз сарыф итә торган лампалар сатып алу;

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган, җыенда катнашучылар исемлегенә 542 кеше кертелде,
тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 377 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" позициясе өчен халык җыенында катнашучы 359 кеше тавыш бирде;
"ЮК" позициясе өчен халык җыенында катнашучы 18 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге составына керүче Яңа Арыш авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.
2. Гражданнар җыенында куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: "Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең Яңа Арыш авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм

тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Яңа Арыш авылында юллар ремонты өчен вакланган таш сатып алуга;
- транспорт хезмәтләренә түләүгә;
- кышкы чорда Яңа Арыш авылында юлларны карап торуга;
- янгын сүндерү җиңсәсе сатып алу;
- энергияне аз сарыф итә торган лампалар сатып алу."

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Яңа Арыш авылы, Мәктәп урамы, 30 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге составына керүче Яңа Арыш авылы торак пунктында үткән гражданнар җыенын әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Зарипов Х.С.

Яңа Арыш авыл җирлеге башлыгы: Зарипов Х.С.

СОВЕТ НОВОАРЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1634001038 ЯҢА АРЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ